ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ОКТЯБРЬСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Центральная, д.7, пос. Октябрьский,
422580

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ОКТЯБРЬСКИЙ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
Декабристлар ур., 35 нче йорт, Печище авылы,
422592

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

**28.03.2019** **40**

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 3

пос. Октябрьский

**Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлеге торак пунктларының территорияләрен санитар-экологик чистарту буенча икеайлык үткәрү турында**

Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеге торак пунктларының территорияләрен төзекләндерү һәм санитар чистарту эшләрен оештыру һәм халыкның экологик иминлегенә җавап бирерлек хәлгә китерү өчен эшләр башкаруны оештыру өчен, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 26.03.2010 № 301 карарын үтәү максатыннан,

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Октябрьский авыл җирлеге торак пунктлар территорияләрен 2019 елның 1 апреленнән 31 маена кадәр төзекләндерү һәм санитар - экологик чистарту икеайлыгын (алга таба – икеайлык) игълан итәргә.

2. Октябрьский авыл җирлеге торак пунктларын төзекләндерү буенча 2019 елга комиссия төзергә (кушымта № 1).

3. Октябрьский авыл җирлеге торак пунктларын төзекләндерү буенча 2019 елга чаралар планын расларга (кушымта №2).

4. Октябрьский авыл җирлеге территориясендә урнашкан предприятие, оешма һәм учреждение җитәкчеләренә, милек формасына бәйсез рәвештә, якын-тирә территорияне төзекләндерү һәм санитар чистарту эшен оештырырга тәкъдим итәргә. Урыннарда агач һәм куаклар утырту, биналарның фасадларын ремонтлау эшен оештырырга.

5. Нинди хокукка карамастан, авыл җирлеге территориясендә күчемсез милек булган гражданнарга йорт яны территорияләрен санитар чистарту буенча эш үткәрергә тәкъдим итәргә.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Октябрьский авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземә калдырам.

**Татарстан Республикасы**
**Югары Ослан муниципаль районының**
**Октябрьский авыл җирлеге Башлыгы** **Ш.Р. Азизов**

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Октябрьский авыл   җирлеге Башкарма
комитетының №40 28.03.2019 ел карарына
Кушымта №1

**Октябрьский авыл җирлеге торак пунктларын төзекләндерү буенча комитет составы**

| | | |
|---|---|---|
| 1. | Азизов<br>Шамиль Рамисович | Октябрьский авыл җирлеге Башлыгы |
| 2. | Мухамадеева<br>Юлия Валерьевна | «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Үзәкләштерелгән клуб системасы» МБУ №2 Октябрьский мәдәният йорты филиалы мөдире |
| 3. | Нуриева<br>Айгуль Фаритовна | «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Үзәкләштерелгән клуб системасы» МБУ №3 Яңа Болгар мәдәният йорты филиалы мөдире |
| 4. | Каландарова<br>Мухаббат Каршиевна | «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Үзәкләштерелгән клуб системасы» МБУ №5 Матюшино мәдәният йорты филиалы мөдире |
| 5. | Гадельшин<br>Ильгизар Анварович | 7 нче номерлы Матюшино бермандатлысайлау округы буенча Октябрьский авыл җирлеге Советы депутаты |
| 6. | Лутфуллин<br>Масгут Гилемханович | 2 нче номерлы Октябрьский бермандатлы сайлау округы буенча Октябрьский авыл җирлеге Советы депутаты |

**Татарстан Республикасы**
**Югары Ослан муниципаль районының**
**Октябрьский авыл җирлеге Башлыгы** **Ш.Р. Азизов**

Татарстан Республикасы Югары Ослан
муниципаль районы Октябрьский авыл
җирлеге Башкарма комитетының
№40 28.03.2019 ел карарына
Кушымта №2

**Октябрьский авыл җирлегендә 01.04.2019 елдан 31.05.2019 елга кадәр икеайлык чорында санитар-экологик хәлне яхшырту чаралары**

**ПЛАНЫ**

| Чаралар исеме | Үткәрү датасы | Җаваплылар |
|---|---|---|
| Авыл җирлеге территориясендә рөхсәтсез чүплекләрне ачыклау һәм бетерү буенча эшләр башкару | даими | Авыл җирлеге Башлыгы, оешма һәм учреждение җитәкчеләре |
| Авыл җирлеге территориясе буйлап уза торган федераль һәм республика әһәмиятендәге трасса буенда чүп җыю | ике атнага бер тапкыр | Авыл җирлеге Башлыгы, оешма һәм учреждение җитәкчеләре |
| Авыл җирлеге торак пунктлары территориясендә чүп-чар җыю, торак пунктларга керү юлы кырларыннан чүп-чар җыю | даими | Авыл җирлеге Башлыгы, авыл җирлеге Советының депутатлар корпусы, халык, оешма һәм учреждение җитәкчеләре |
| Авыл җирлеге территориясендә федераль һәм республика әһәмиятендәге трасса буенда баганалар агарту | май аеның беренче декадасы | Авыл җирлеге Башлыгы, оешма һәм учреждение җитәкчеләре |
| Авыл җирлеге территориясендә торак пунктлар эчендә баганалар агарту | май аеның беренче декадасы | Авыл җирлеге Башлыгы, авыл җирлеге Советының депутатлар корпусы, халык |
| Авыл җирлеге территориясендә федераль һәм республика әһәмиятендәге трасса буенда чүп үләнен чабу | кирәк булганда | Авыл җирлеге Башлыгы, оешма һәм учреждение җитәкчеләре |
| Авыл җирлеге территориясендә торак пунктлар эчендә чүп үләнен чабу | кирәк булганда | Авыл җирлеге Башлыгы, авыл җирлеге Советының |

| | | |
|---|---|---|
| | | депутатлар корпусы, халык, оешма һәм учреждение җитәкчеләре |
| Авыл җирлеге территориясендә урнашкан учреждение, предприятие биналарының фасадларын ремонтлау | Апрель ае буе | оешма һәм учреждение җитәкчеләре |
| Авыл җирлеге муниципаль милкендә булган шәхси сектор һәм торак фонд йортларының фасадларын ремонтлау | Апрель ае буе | Авыл җирлеге Советының депутатлар корпусы, халык |
| Авыл җирлеге территориясендә урнашкан зиратларны төзекләндерү буенча өмәләр оештыру һәм үткәрү (коймаларны ремонтлау, коймаларны буяу, чүп-чар чыгару) | май аеның икенче декадасы | Авыл җирлеге Советының депутатлар корпусы, халык |
| Октябрьский авыл җирлеге территориясендә урнашкан учреждениеләр, предприятиеләр һәм оешмалар территорияләрен санитар-экологик чистарту, төзекләндерү һәм яшелләндерү | 20.04.2019-01.05.2019 | оешма һәм учреждение җитәкчеләре |
| Авыл җирлеге чишмәләрен төзекләндерү | май аеның беренче декадасы | Авыл җирлеге Советының депутатлар корпусы, халык |
| Урам утларын ремонтлау (яктырткычларны алмаштыру, урам утларының өстәмә лампалары урнаштыру, терәкләр урнаштыру) | кирәк булганда | Авыл җирлеге Башлыгы |
| Октябрь авыл җирлеге торак пунктларында яшел үсентеләр утырту. | 20.04.2019-01.05.2019 | Авыл җирлеге Башлыгы, оешма һәм учреждение җитәкчеләре |
| Балалар өчен уен мәйданчыкларын төзекләндерү | 20.04.2019-01.05.2019 | Авыл җирлеге Башлыгы, халык |
| Авыл җирлеге территориясеннән каты көнкүреш калдыкларын җыю, туплау һәм чыгаруны оештыру мәсьәләсе буенча халык белән эшне активлаштыру | 20.04.2019-01.05.2019 | Авыл җирлеге Башлыгы, авыл җирлеге Советының депутатлар корпусы, халык, оешма һәм учреждение җитәкчеләре |

| | | |
|---|---|---|
| Җирлек эчендәге юлларны төзекләндерү (грейдерлау, вак таш җәю) | 20.04.2019-01.05.2019 | Авыл җирлеге Башлыгы, население |
| Авыл җирлеге территориясендә җәяүлеләр күперләрен ремонтлау һәм төзекләндерү | кирәк булганда | Авыл җирлеге Башлыгы, авыл җирлеге Советының депутатлар корпусы, халык |
| Ключище, Матюшино торак пунктларында Идел елгасы яр буе линиясен чисталыкта тоту | даими | Авыл җирлеге Башлыгы |
| Авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү кагыйдәләрен бозуларны ачыклау һәм булдырмау буенча эшне көчәйтергә | даими | Авыл җирлеге Башлыгы, вәкаләтле вәкил-авыл җирлегенең җаваплы затлары, Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының административ комиссиясе вәкилләре |

**Татарстан Республикасы**
**Югары Ослан муниципаль районының**
**Октябрьский авыл җирлеге Башлыгы** **Ш.Р. Азизов**